СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРЫ

2020 елның 30 октябре № 2

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы

карар кабул итте:

1. 2020 елның 17 ноябре сәгать 15.00 гә, Үзәк урамдагы 84 йортта Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылындагы Үзәк урам,47-83 (урамның так ягы), 12-80 (урамның җөп ягы); Совет урамы 121-129 йортларда яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 18 ноябренә сәгать 15.00 да, Совет урамы,25 номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылындагы Совет урамы 1-43 йортларда яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2020 елның 19 ноябренә сәгать 14.00 да, Үзәк урам,89А номерлы адрес буенча урнашкан Ленино авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылындагы Җиңүнең 40 еллыгы, Заозерная урамнары, Үзәк урамның 1/1-45 (урамның так ягы), 6,10 йортларда; Совет урамы 44-118 йортларда яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык җыенын үткәрү өчен Ленино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе территориаль билгеләр буенча башкарылырга тиеш.

5. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку

формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Ленино авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Совет урамы буенча һәм аның янәшәсендәге тыкрыкларны норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү системасын һәм инфраструктура объектларын проектлау, ремонтлау, карап тоту (сатып алу), килешү буенча эшләр өчен түләү, техник документацияне эшләү);
- Совет урамы, Җиңүнең 40 еллыгы урамына балалар уен мәйданчыгын сатып алу, реконструкцияләү һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм килешү буенча эшләү өчен түләү).

"РИЗА" «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге Башлыгы М.Г. Дубровина

СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ